22 сентябрь конне Саранск шәһәрендә «Авылым тавышлары» X Республика татар жыры фестиваль–конкурсы узды.

Юбилей фестивалендә Саранск һәм Мордовия районнарыннан татар халык жыр-ларын, шулай ук заманча эстрада хитларын башкаручы ин яхшы үзешчән артистлар катнашты. Концертта аерым башкаручылар, фольклор, вокаль ансамбльләр чыгыш ясады. «Авылым тавышлары» фестивале ел саен яна исемнәр ача, ә инде таныш башкаручылар яна репертуарлары белән гажәпләндерә. Шулай, Рузаевка районында урнашкан зур татар авылы жыры халыкны үзенә жәлеп итте. Бу жыр ин яхшы башкарылган булуы белән халык ана беренче урын бирде. Ә нинди ул жыр диярсез, каян килгән дип сорарсыз?

Бу сораулар мине дә кызыксындырды һәм жавап эзли башладым. Жавапны таптым, сезгә дә ишеттерәм.

Ярышта Рузаевка районы классик якташ язучыбыз Шәриф Камал туган Татар Пешләсе авылында туып-үскән Диана Марат кызы Багапова «Күнелем сина ята» дигән жыры белән лаеклы икенче урын яулады. Ә Зульфия Шәмил кызы Гундина сүзләренә һәм музыкасына язылган «Татар Пешләсе» дигән жырны Диана Марат кызы Багапова житәкчелегендәге «Миләшләрем» ансамбле «Автор жырларының ин яхшы башкаручылары» («За лучшее исполнение авторской песни») номинациясендә чынлап та ин-ин яхшылар титулы яуладылар. Халык аны ин матур һәм оста башкарылган жыр, ди.

Жырны язган Зульфия Шәмил кызы - ансамбль вәкиле, ижади кеше. Тормыш иптәше белән оч матур бала - Арыслан, Салават, Камилланы тәрбияләп үстерәләр. Хәтта жыр язарга, коен һәм сүзләрен ижат итәргә вакыт таба. Рузаевка районы Татар Пешлә авылы главасы Ринат Дәүлюк улы Шабаев Зульфия Шәмил кызы Гундинанын «Татар Пешләсе» дигән жырын авыл гимнына тин дип тә атый һәм шулай булачак, ахры.

Жыр - халык лирикасынын ин таралган торе, сүз белән койнен үзара үрелүенә нигезләнгән, жырлап башкарыла торган шигъри-музыкаль әсәр. Зульфиянен туган Шәриф Камаллы Пешлә авылына булган мәхәббәте, кичерешләре – сүз белән койдән тора. Жырнын топ функциясе дә халыкнын һәм шәхеснен рухи доньясын, фикер һәм кичерешләрен чагылдыру. Татар жырынын тамыры – халык койләрендә, дибез. Бу очракта шулай. Ә ансамбль житәкчесе Марат кызы Диана жырны югары күтәреп, олы профессионалларга тин башкаруга ирешә; татар милли монынын нечкәлекләрен күнелләребезне тибрәндерерлек итеп теләсә кайсы жырны башкара, житәкләгән ансамблен дә югары унышларга менгерә. Диана гаиләдә бердән-бер бала булып

тәрбияләнә, Татар Пешлә урта мәктәбен тәмәм-лый, жырга-монга тартылып vсә - мәктәп концертларында беренче дебютларын vткәрә. Бvген гаиләсе анын мәдәният олкәсендә булган унышларына шатланып яшиләр. Шундый ижади кешеләребез авылларыбызны яшәтә дә. Бу очракта олы сәхнәләргә мендерде.

Н.Хәлил